| СОВЕТ АЛЕКСЕЕВСКОГО ГОРОДСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АЛЕКСЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛЕКСЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ АЛЕКСЕЕВСК ШӘҺӘР ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |
|---|---|---|
| **РЕШЕНИЕ** | | **КАРАР** |
| 07.06.2024 | п.г.т. Алексеевское | №96 |

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Алексеевск шәһәр җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга кертелгән үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән бәйле рәвештә һәм Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы «Алексеевск шәһәр җирлеге» Уставының XVI бүлегенә ярашлы рәвештә

**Алексеевск шәһәр җирлеге Советы карар бирде:**

1. «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы «Алексеевск шәһәр җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Алексеевск муниципаль районы Алексеевск шәһәр җирлеге Советы Карары проектын беренче укылышта кабул итәргә.
2. «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы «Алексеевск шәһәр җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Алексеевск шәһәр җирлеге Советы карарына гражданнарның тәкъдимнәрен исәпкә алу тәртибен һәм гражданнарның аны тикшерүдә катнашуын расларга. (2 нче кушымта).
3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында(pravo.tatarstan.ru), Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында (https://alekseevskiy.tatarstan.ru/) бастырып чыгарырга.
4. Законлылык, хокук тәртибе, табигатьне саклау, экология һәм җирдән файдалану мәсьәләләре буенча даими депутат комиссиясенә (Добрецов О. Н.) әлеге карарга кергән тәкъдимнәрне исәпкә алу, гомумиләштерү һәм карауны йөкләргә.
5. Алексеевск муниципаль районы Алексеевск шәһәр җирлеге Советы депутатларының карар проектына тәкъдимнәре төзәтмәләр рәвешендә комиссиягә 2024 елның 25 июненә кадәр кертелә.
6. Карар проектына гражданнарның тәкъдимнәре комиссиягә язма рәвештә Ф.И. А., туган елы, авторның адресы күрсәтелеп,Алексеевск штб, Павелкин урамы, 18 йорт адресы буенча җибәрелә.
7. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Алексеевск шәһәр җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү

буенча гавами тыңлауларны 26.06.2024 елга 11-00 сәгатьтә Алексеевск шәһәр җирлеге башкарма комитеты бинасында билгеләргә ,адресы :Татарстан Республикасы, Алексеевск муниципаль районы, Алексеевск шәһәр тибындагы бистәсе, Павелкин урамы, 18 йорт .

Гавами тыңлаулар Алексеевск муниципаль районы Алексеевск шәһәр җирлеге Советының 23.11.2006 ел №28 карары белән расланган Алексеевск муниципаль районы Алексеевск шәһәр җирлегендә гавами тыңлауларны оештыру һәм үткәрү тәртибенә ярашлы рәвештә үткәрелә.

8. Комиссиягә җирлек Советы депутатларының төзәтмәләрен һәм гражданнарның карар проектына тәкъдимнәрен өйрәнергә һәм гомумиләштерергә, аларны эшләп бетерергә һәм 2024 елның 27 июненә кадәр җирлек Советы каравына кертергә.

9. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Алексеевск шәһәр җирлеге башлыгы урынбасары В.В. Увакинага йөкләргә .

10. Әлеге карар, әгәр федераль законда башкасы каралмаган булса, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 44 статьясының 8 өлеше нигезендә үз көченә керә.

11. Әлеге карарга кушымтаның 6 статьясының 1 өлеше 29 пункты һәм 52 статьясының 1 өлеше тугызынчы пунктының 3 абзацы нигезләмәләре 01.09.2024 елдан үз көченә керә.

**Алексеевск шәһәр**
**җирлеге Башлыгы,**
**Совет Рәисе** **С.А. Демидов**

Алексеевск шәһәр җирлеге
Советының
7.06.2024 ел,№ 96
карарына 1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы «Алексеевск шәһәр җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында » Совет карары проекты буенча гражданнар тәкъдимнәрен исәпкә алу тәртибе**

1. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының « Алексеевск шәһәр җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Совет карары проектына тәкъдимнәр Алексеевск шәһәр җирлеге советына түбәндәге адрес буенча кертелә: ТР, Алексеевск районы, Алексеевск штб, Павелкин урамы, 18 йорт адресы буенча язма рәвештә төзәтмәләр таблицасы рәвешендә:

| № | Пункт, пунктча | Карар проекты тексты | Төзәтмә тексты | Төзәтмә исәпкә алынган проект тексты | Төзәтмә авторы поправки (Ф.И.А., адресы, уку ,эш урыны) |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |

Тәкъдимнәр эш көннәрендә 8.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр, гавами тыңлаулары уздыруга 7 көннән дә соңга калмыйча кабул ителә.
2. Гавами тыңлауларда чыгыш ясау хокукы белән катнашу өчен гаризалар ТР, Алексеевск районы, Алексеевск штб, Павелкин урамы, 18 йорт адресы буенча язма рәвештә яки почта аша бирелә.
Гаризалар эш көннәрендә 8.00 дән 17.00 гә кадәр кабул ителә
3. Гражданнарның тәкъдимнәре эшче төркем тарафыннан теркәлә һәм карау өчен Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Алексеевск шәһәр җирлеге» муниципаль берәмлеге Советына һәм Башлыгына тапшырыла.

**Алексеевск шәһәр җирлеге Башлыгы, Совет Рәисе** **С.А.Демидов**

Алексеевск шәһәр җирлеге
Советының
7.06.2024 ел,№ 96
карарына 2 нче кушымта

**«Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы «Алексеевск шәһәр җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында»Совет карары проектын тикшерүдә гражданнарның катнашуы**
**ТӘРТИБЕ**

1. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Алексеевск шәһәр җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Совет карары проектын карау буенча гавами тыңлаулар Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Алексеевск шәһәр җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына ярашлы рәвештә үткәрелә.
2. Гавами тыңлаулар Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, прокуратура, белгечләр, сәяси партияләр, башка иҗтимагый берләшмәләр вәкилләре, белгечләр, кызыксынган затлар чакырылып үткәрелергә мөмкин.
3. Гавами тыңлауларда Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Алексеевск шәһәр җирлеге» муниципаль берәмлегенең теләсә кайсы кешесе катнашырга хокуклы.
4. Катнашучыларны теркәү гавами тыңлаулар башланганчы 1 сәгать алдан башлана.
5. Гавами тыңлауларда Уставка үзгәрешләр проектына кергән тәкъдимнәрне исәпкә алу, гомумиләштерү һәм карау буенча оештыру комитеты рәисе рәислек итә.
6. Гавами тыңлаулар рәислек итүченең кереш сүзе белән ачыла, ул катнашучыларга фикер алышу мәсьәләләренең асылы, тыңлаулар үткәрү тәртибе турында хәбәр итә.
7. Гавами тыңлаулар беркетмәсен оештыру комитеты сәркатибе алып бара.
8. Төп доклад белән Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында карар проектын эшләү буенча оештыру комитеты җитәкчесе чыгыш ясый.
9. Төп докладтан соң сүз гавами тыңлауларда катнашу өчен чакырылган катнашучыларга бирелә.
10. Гавами тыңлауларда катнашучылар чыгыш ясау хокукы белән гариза бирү вакытына бәйле рәвештә үз тәкъдимнәрен чиратлап дәлилләү өчен чакырыла.
11. Гавами тыңлауларда катнашучыларның чыгышлары расланган регламент нигезендә дәвам итәргә тиеш.
12. Җәмәгать тыңлауларында катнашучылар чыгыш тәмамланганнан соң чыгыш ясаучыларга сораулар бирергә хокуклы.
13. Гавами тыңлауларда катнашучылар гавами тыңлаулар барышына тыкшынырга, аларны өзәргә һәм аларны үткәрүгә комачауларга хокуклы түгел.
14. Гавами тыңлауларны үткәргәндә тәртип саклау гавами тыңлауларда катнашу өчен мәҗбүри шарт булып тора.

15.Гавами тыңлауларны үткәрү тәртибе бозылган очракта, рәислек итүче аларны тыңлаулар уздырылган бинадан чыгаруны таләп итәргә хокуклы.

16. Чыгышлар тәмамлангач, рәислек итүче оештыру комитеты секретаре алдында җәмәгать тыңлаулары барышында әйтелгән тәкъдимнәрне, тәкъдимнәрне төгәлләү өчен сүз бирә ала.

17. Гавами тыңлауларда катнашучыларның барлык искәрмәләре һәм тәкъдимнәре гавами тыңлаулар беркетмәсенә кертелә.Гавами тыңлаулар беркетмәсенә оештыру комитеты рәисе һәм секретаре кул куя һәм Алексеевск шәһәр җирлеге Советы материалларында билгеләнгән тәртиптә саклана.

18. Гавами тыңлаулар нәтиҗәләре буенча нәтиҗә гавами тыңлаулар секретариаты тарафыннан әзерләнә һәм халыкка җиткерелергә тиеш.

19. Гавами тыңлауларны оештыруны һәм матди-техник тәэмин итүне Алексеевск шәһәр җирлеге Советы башкара.

**Алексеевск шәһәр**
**җирлеге Башлыгы,**
**Совет Рәисе** **С.А.Демидов**

Алексеевск шәһәр җирлеге
Советының 7.06.2024 ел,№ 96
карарына 3 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы «Алексеевск шәһәр җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр**

**1. 6 статьяда:**

а) **1 өлешендәге 29 пунктта** «Җирлек территориясендә дәвалау-сәламәтләндерү урыннарын һәм җирле әһәмияттәге курортларны булдыру, үстерү һәм саклауны тәэмин итү, шулай ук» төшереп калдырырга;

б)**1 өлешендәге 31 пунктны** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«31) балалар һәм яшьләр белән эшләү чараларын оештыру һәм гамәлгә ашыру, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруда катнашу, яшьләрнең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү һәм яклау чараларын эшләү һәм гамәлгә ашыру, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруның төп юнәлешләре буенча муниципаль программаларны эшләү һәм гамәлгә ашыру, җирлектә яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруны мониторинглауны оештыру һәм гамәлгә ашыру;».

**2. 22 статьяда:**

а) **5 нче пунктны** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Гавами тыңлауларны үткәрү турында карар, аларны үткәрү вакытын һәм урынын күрсәтеп, һәм гавами тыңлауларга чыгарыла торган тиешле муниципаль норматив хокукый акт проекты, гавами тыңлауларын үткәрү көненә кадәр 7 көннән дә соңга калмыйча, бастырып чыгарылырга (халыкка җиткерелергә), шул исәптән «дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) Бердәм порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырылырга тиеш.»;

б) **6 нчы пунктны** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Гавами тыңлаулар үткәрү турында карар һәм муниципаль норматив хокукый акт проекты басылып чыккан көннән(халыкка җиткерелгәннән) башлап район халкы җирлек Башлыгына гавами тыңлауларга чыгарылган муниципаль норматив хокукый акт мәсьәләсе яки проекты буенча, шул исәптән «дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) Бердәм порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасы аша, тәкъдимнәр һәм искәрмәләр җибәрергә хокуклы. Искәрмәләр һәм тәкъдимнәр юнәлеше гавами тыңлаулар уздырылганчы 2 эш көненнән дә соңга калмыйча тәмамлана. Җирлек Башлыгы килгән тәкъдимнәрне һәм искәрмәләрне гомумиләштерүне һәм аларны җәмәгать тыңлауларында катнашучыларга җиткерүне оештыра.»;

в)**9 нчы** пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9.Гавами тыңлаулар нәтиҗәләре, шул исәптән кабул ителгән карарларның мотивацияле нигезләмәсе, «дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) Бердәм порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасында гавами тыңлаулар уздырылганнан соң 5 көннән дә соңга калмыйча бастырылырга (халыкка җиткерелергә) тиеш.»;

**3. 33 статьяда:**

а) **8 нче һәм 9 нчы пунктларда** «Татарстан Республикасы Президенты » сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләре белән алыштырырга;

б) **12 нче пунктны** төшереп калдырырга;

**4. 45 нче статьяның 1 нче пунктында** «Татарстан Республикасы Президентын » сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисен» сүзләре белән алыштырырга;

**5. 52 статьяда:**

а) **1 нче өлешнең 5 нче пунктының алтынчы абзацын** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- балалар һәм яшьләр белән эшләү буенча чаралар оештыра һәм гамәлгә ашыра, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруда, яшьләрнең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү һәм яклау чараларын эшләүдә һәм гамәлгә ашыруда, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруның төп юнәлешләре буенча муниципаль программаларны эшләүдә һәм гамәлгә ашыруда катнаша, җирлектә яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруны мониторинглауны оештыра һәм гамәлгә ашыра;";

б) **1 нче өлешнең 3 нче пунктының тугызынчы абзацын** «җирлек территориясендә дәвалау-сәламәтләндерү урыннарын һәм җирле әһәмияттәге курортларны булдыра, үстерә һәм саклауны тәэмин итә» төшеререп калдырырга

**6. 58 статьяның 2 пунктының 2 пунктчасында** «Татарстан Республикасы Президентын» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисен» сүзләре белән алыштырырга;

**7. 72 статьяның 1,4,5,6,7 пунктларында, 12 ,15 пунктындагы 1 пунктчасында** «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләре белән алыштырырга;

**8. 62 статьяны** төшереп калдырырга

**9. 72 нче статьяның 3 нче пунктында** «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләре белән алыштырырга;

**10. 74 статьяда:**

а) **1 өлешнең 1 пунктын** «федераль законнар белән билгеләнгән очраклардан тыш» дигән сүзләр белән тулыландырырга;

б) **1 өлешнең 2 пунктында** «яки белә торып дөрес булмаган яки тулы булмаган мәгълүматны бирү» сүзләрен «, федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш, белә торып тулы булмаган мәгълүматны бирергә, яки белә торып дөрес булмаган мәгълүматны бирергә» дигән сүзләр белән алыштырырга;

в)**2 нче өлешне** «федераль законнар белән билгеләнгән очраклардан тыш» дип тулыландырырга;.

**11. 83 статьяны** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«83 статья. Муниципаль хокукый актларны халыкка җиткерү һәм аларның үз көченә керүе тәртибе.

1. Кеше һәм гражданның хокукларына, ирекләренә һәм бурычларына кагылышлы муниципаль норматив хокукый актлар, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Алексеевск шәһәр җирлеге» муниципаль берәмлеге оештыручы булып торган оешмаларның хокукый статусын билгеләүче муниципаль норматив хокукый актлар, шулай ук җирле үзидарә органнары арасында төзелә торган килешүләр рәсми рәвештә халыкка җиткерелгәннән соң үз көченә керә.

2. Муниципаль норматив хокукый актның, шул исәптән җирле үзидарә органнары арасында төзелгән килешүнең рәсми игълан ителүе булып аларның:

1) Тулы текстны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында рәсми рәвештә бастырып чыгару (https://pravo.tatarstan.ru; ЭЛ

массакүләм мәгълүмат чарасы буларак теркәлү турында таныклык no ФС77-60244 17.12.2013 элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәт (Роскомнадзор)тарафыннан бирелгән;

2) Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Алексеевск шәһәр җирлеге» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру https://alekseevskiy.tatarstan.ru/alekseevskiy/alekseevskoe.htm;

3) адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштыру:

- ТР Алексеевск муниципаль районы Алексеевск шәһәр җирлеге Башкарма комитетының административ бинасы: Алексеевск штб, Павелкин урамы, 18 йорт;

-Күп функцияле үзәк, Алексеевск штб, Совет мәйданы, 2 нче йорт;

-район мәдәният йорты, Алексеевск штб, Совет мәйданы, 1а йорт;

-үзәк китапханә, Алексеевск штб, Казаков урамы, 12 йорт;

3. Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталына гражданнарның керүен тәэмин итү өчен «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренә тоташу пунктлары эшли,адреслар буенча:

- ТР Алексеевск муниципаль районы Алексеевск шәһәр җирлеге Башкарма комитетының административ бинасы: Алексеевск штб, Павелкин урамы, 18 йорт;

4. Муниципаль норматив хокукый актлар, җирле үзидарә органнары арасында төзелә торган килешүләр, муниципаль хокукый актлардан яки Федераль закон белән чикләнгән мәгълүматлар булган аерым нигезләмәләрдән тыш, имзаланганнан соң 10 көн эчендә халыкка җиткерелә.

5. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Алексеевск шәһәр җирлеге» муниципаль берәмлегенең салымнар һәм җыемнар турындагы норматив хокукый актлары Россия Федерациясе Салым кодексына ярашлы рәвештә үз көченә керә.

6. Әлеге статьяның 1 пунктында күрсәтелмәгән муниципаль хокукый актлар, әгәр акт үзе башканы билгеләмәсә, имзаланган көннән үз көченә керә.

7. «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә тиешле сайтларның домен исемнәре һәм аларны массакүләм мәгълүмат чаралары буларак теркәү турындагы мәгълүматлар күрсәтелгән вакытлы матбугат басмалары, челтәр басмалары исемлеге, аларда муниципаль хокукый актлар, шул исәптән җирле үзидарә органнары арасында төзелгән килешүләр халыкка җиткерелә (рәсми бастырудан тыш) , Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы «Алексеевск шәһәр җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгының хокукый актын бастырып чыгару юлы белән гомум мәгълүматка җиткерелә.».

**Алексеевск шәһәр**
**җирлеге Башлыгы,**
**Совет Рәисе** **С.А. Демидов**